| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.12.2025 п.г.т.Алексеевское № 575

**2026 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсенең 4 өлешенә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау хакында» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгына туры китереп

**карар бирәм:**

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен һәм торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләменең иң чик индексын расларга:
- шәһәр җирлеге - 12% күләмендә,
- авыл җирлекләре - 11% күләмендә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга..

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Е.Н.Мельниковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы** **Е.А. Хәмзина**